ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 октябрь 2025ел № 8862

Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3670 номерлы Карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3670 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2021 елның 23 ноябрендәге 7629 номерлы, 2024 елның 12 июлендәге 4577 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 3, 4 пунктчалар өстәргә:

«3) эшләрне башкару срокларын озайту турында килешү күчермәсен теркәп (эшләр подрядчы тарафыннан башкарылган очракта), яңа чорга эшләрне башкару графигы (эшләрнең сроклары үзгәргән очракта);

4) башкарылган һәм тәмамланмаган эшләрнең күләмен күрсәтеп, башкарыла торган эшләр өчен объектның фотофиксациясе.»;

2) 2.5.6 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 3, 4 пунктчалар өстәргә:

«3) инженерлык коммуникацияләрен эксплуатацияләү, автомобиль юлларын эксплуатацияләү өчен җаваплы хезмәтләр, җир эшләре башкарылган җир участокларының саклык зоналарын баланста тотучылар белән килештерү;

4) башкарылган һәм тәмамланган эшләрнең күләмен күрсәтеп, объектның фотофиксациясе.»;

3) 2.5.8 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 3 пунктча өстәргә:

«3) Башкарма комитетка шәхсән яки почта элемтәсе аша кәгазь чыганакта. Гариза һәм теркәлә торган документлар почта элемтәсе аша җибәрелгәндә, билгеләнгән тәртиптә таныклана.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов